| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан** | **Татарстан Республикасы** |
| **СОВЕТ** | **САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ** |
| **ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**423370, Татарстан Республикасы, Сарман районы, Янурыс авылы, Ленин ур., 43 а, тел.4-10-19 ИНН 1636001403 КПП 163601001 Р/С 40481050000057002З ОГРН 1031604000757 ОКАТО 92253884000**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның 19 марты № 4

Гавами тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге халкының җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтләр бирү, урамнарга исемнәр бирү мәсьәләләре буенча фикерләрен һәм мәнфәгатьләрен ачыклау һәм исәпкә алу максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Сарман муниципаль районының 2013 елның 12 февралендәге 4 номерлы карары белән расланган Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 19 статьясы, 19 ст.7 пунктына таянып,карар бирәм:

1. Халык алдында тыңлаулар билгеләргә:

1.1. Янурыс авылы, Ленин ур., 40 а адресы буенча урнашкан 16:36:050101:26 кадастр номерлы,җитештерү һәм административ биналар, төзелешләр, коммуналь хуҗалык, материаль-техник, азык-төлек белән тәэмин итү, сату һәм әзерләү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә Юнысов Булат Хәмит улына шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлегеннән файдалану рөхсәте бирү буенча.

2. Билгеләргә:

- гавами тыңлауларны оештыручы - Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге башкарма комитеты;
- гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 2016 елның 19 апрелендә 15.00 сәгатьтә;
- үткәрелү урыны - Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авылы Мәдәният йорты бинасы (адресы: Янурыс авылы, Ленин ур.);

- язма тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертелә ала торган адрес - Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авылы, Ленин урамы, 43а, Янурыс авыл җирлеге башкарма комитеты (эш көннәре 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр).

3. Әлеге карарны махсус информация стендларында һәм «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Янурыс авыл җирлеге

Башлыгы Мөхәммәдиева А.А